**Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районының**
**«Мордва Афонькәсе авыл җирлеге»**
**муниципаль берәмлеге**
**гражданнар җыены**
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Мордва Афонькәсе авыл җирлегенең Лагерка торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**30 октябрь 2024 ел** **№ 5**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2024 елның 30 октябрендә киләсе мәсьәлә буенча үткәрелгән гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде: «2025 елда Чирмешән муниципаль районы Мордва Афонькәсе авыл җирлегенең Лагерка торак пункты территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 500 сум күләмендә үзара салым кертергә, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүчеләрдән, Луганск халык республикасында һәм Донецк халык республикасында махсус операциядә булган затлардан тыш һәм алынган чараларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә җибәрү белән килешәсезме:

- **торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү** (юл кырыйларын чабу, бензин, триммер өчен запас частьләр сатып алу һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү, юлларны грейдерлау, кышкы вакытта урамнарны кардан чистарту, ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу, тракторчыга исәпләнгән хезмәт хакы), Лагерка торак пунктында югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу;
- **урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны ремонтлау** (Лагерка торак пунктында урамнар яктырткычларын монтажлау, ремонтлау, алмаштыру)

«РИЗА» «КАРШЫ».

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенының 190 катнашучысы кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 97 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенының 97 катнашучысы тавыш бирде;
«Юк» позициясе өчен гражданнар җыенының 0 катнашучысы тавыш бирде.
Бәян ителгәннәр нигезендә халык җыены карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Мордва Афонькәсе авыл җирлегенең Лагерка торак пунктында халык җыены булып узган, халык җыены нәтиҗәләре - чын дип таныырга.

2. Киләсе мәсьәлә буенча: «2025 елда Чирмешән муниципаль районы Мордва Афонькәсе авыл җирлегенең Лагерка торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 500 сум күләмендә үзара салым кертергә, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүчеләрдән, Луганск халык республикасында һәм Донецк халык республикасында махсус операциядә булган затлардан тыш» һәм алынган чараларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә җибәрергә:

- **торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү** (юл кырыйларын чабу, бензин, триммер өчен запас частьләр сатып алу һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү, юлларны грейдерлау, кышкы вакытта урамнарны кардан чистарту, ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу, тракторчыга исәпләнгән хезмәт хакы), Лагерка торак пунктында югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу;

- **урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны ремонтлау** (Лагерка торак пунктында урамнар яктырткычларын монтажлау, ремонтлау, алмаштыру)

3. Җыенның нәтиҗәләрен мәгълүмати стендларда урнаштыру юлы белән игълан итәргә: Лагерка авылы, Школьная урамы, 22 нче йорт, Чирмешән муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми интернет сайтында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче
Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Мордва Афонькәсе авыл җирлеге башлыгы А.И.Митяев